| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |
| **ПРИКАЗ**<br>20.10.2025 | Казан ш. | **БОЕРЫК**<br>1250-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча комиссия турында нигезләмә раслау хакында» 07.04.2022 ел, №258-п боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 05.07.2022 ел, №577-п, 10.04.2023 ел, №428-п, 06.06.2023 ел, №695-п, 06.05.2025 ел, №462-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча комиссия турында нигезләмәдә:

3.1 пунктта «12» саннарын «13» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча комиссия составында:

комиссия составыннан В.А.Долговны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Назаров Наил Госман улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгын – комиссия рәисе урынбасарын;

Клементьева Диана Юрьевнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгын.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле

әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын карау һәм килештерүне оештыру хакында» 2023 елның 5 сентябрендәге 1031-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 06.05.2025 ел, №463-п боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм куллланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын карау комиссиясе турында нигезләмәдә:

3.1 пунктта « 11 «саннарын «13» саннарына алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын карау комиссиясе составында:

комиссия составыннан В.А.Долговны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Назаров Наил Госман улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгын – комиссия рәисе урынбасарын;

Клементьева Диана Юрьевнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгын;

Кузнецов Максим Дмитриевичны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенең әйдәп баручы белгечен.

3. Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенә әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары А.А.Тугушевка йөкләргә.

Министр А. В. Шадриков